**МИНИСТЕРСТВО ЮСТИЦИИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮСТИЦИЯ МИНИСТРЛЫГЫ**

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

07.02.2020 г. Казань № 22од

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләренең коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт
алу тәртибе турында

«Россия Федерациясендә дәүләт граждан хезмәте турында» 2004 елның 27 июлендәге 79-ФЗ номерлы Федераль законның 17 статьясындагы 1 өлешенең 3 пунктының «б» пунктчасы нигезендә боерам:

1.Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алуларның тәкъдим ителә торган тәртибен (алга таба – Тәртип) расларга.

2. Кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге башлыгына:

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләрен әлеге боерык белән таныштырырга;

Тәртипне Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының «Коррупциягә каршы сәясәт» мәгълүмат стендына урнаштырырга.

3. Җәмәгать судьялары эшчәнлеген оештыру-хокукый тәэмин итү бүлеге башлыгына Тәртипне суд участоклары стендларына урнаштыруны оештырырга.

4. Хокукый мәгълүматлаштыру һәм компьютер системалары бүлегенә әлеге боерыкны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Хөкүмәтенең рәсми порталында Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының рәсми сайтындагы «Коррупциягә каршы тору» бүлегенә урнаштырырга.

5. Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчләрен югалткан дип санарга:

«Эш бирүче вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә коммерциячел булмаган оешмалар белән идарәдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яки аларның идарә коллегиаль

органнары составына керүгә рөхсәт бирелү тәртибе турында» 2017 елның 14 июнендәге 01-02/50 нномерлы;

«Эшкә алучының вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәренә Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында коммерциячел булмаган оешмалар белән идарә итүдә бер кеше кулындагы башкарма орган сыйфатында түләүсез нигездә катнашуга яисә аларның идарә коллегиаль органнары составына керүгә рөхсәт бирүнең Татарстан Республикасы юстиция министрының 2017 елның 14 июнендәге 01-02/50 номерлы боерыгы белән расланган тәртибенә үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 26 апрелендәге 52од номерлы».

6. Әлеге боерыкның үтәлешен тикшереп торуны үз карамагымда калдырам.

Министр Р.И. Заһидуллин

Татарстан Республикасы
юстиция министрының
07.02.2020 № 22од
боерыгы белән расланган

Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу тәртибе

1. Әлеге Тәртип Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан хезмәткәрләренең (алга таба – граждан хезмәткәрләре, Министрлык) коммерцияле булмаган оешмалар белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу процелдурасын билгели.

2. Әлеге Тәртип Министрлыктагы алар өчен эш бирүче вәкиле булып Татарстан Республикасы юстиция министры (алга таба – министр) торган Татарстан Республикасы граждан хезмәткәрләренә кагыла.

Әлеге Тәртип граждан хезмәткәрләренең сәяси партия, профессиональ союз органы, шул исәптән Министрлыкның беренчел профсоюз оешмасының сайлаулы органы белән идарә итү, съездда (конференциядә) яки башка төр иҗтимагый оешманың, торак, торак-төзелеш, гараж кооперативы, күчемсез милек хуҗалары иптәшлегенең гомуми җыелышында катнашу очракларына кагылмый.

3. Граждан хезмәткәренең коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашуы мәнфәгатьләр каршылыгына яки вазыйфаи бурычларны үтәгән чакта мәнфәгатьләр каршылыгы килеп чыгу мөмкинлегенә китерергә тиеш түгел.

4. Коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт алу граждан хезмәткәре тарафыннан әлеге Тәртипкә 1 нче кушымта нигезендә язма формада гариза бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

5. Граждан хезмәткәре гаризаны коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә катнашканчы Министрлыкта коррупцион һәм башка төр хокук бозуларны профилактикалау эше өчен җаваплы затка (алга таба – Җаваплы зат) тапшыра.

6. Җаваплы зат гаризаны кергән көнендә әлеге Тәртипкә 2 нче кушымта нигезендәге форма буенча, Журналга терки.

7. Гариза теркәлгән көннән соңгы биш эш көне эчендә Җаваплы зат гаризаны карый һәм аны карау нәтиҗәләре буенча бәяләмә әзерли.

Гаризаны карау барышында Җаваплы зат гаризаны бирүче граждан хезмәткәреннән коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә планлаштырылган катнашу буенча функцияләрне билгели торган язма аңлатмалар һәм документлар сoратып алу хокукына ия.

Бәяләмәдә граждан хезмәткәренә коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү яки рөхсәт бирмәү турындагы җөмлә булырга тиеш.

8. Җаваплы зат бәяләмә һәм башка материаллар (булган очракта) теркәлгән гаризаны коммерцияле булмаган оешма белән идарә итүдә түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт бирү яки рөхсәт бирмәү турында карар кабул итү өчен министрга

карауга тапшыра.

Министр карарны гариза Җаваплы заттан алынган көннән соңгы ике эш көне эчендә кабул итә.

Карар гаризага тиешле резолюцияне салу юлы белән рәсмиләштерелә.

9. Җаваплы зат министр тарафыннан карар кабул ителгәннән соңгы ике эш көне эчендә граждан хезмәткәренә гаризаны карау нәтиҗәләре турында хәбәр итә һәм аңа гаризаның министр имзасы салынган  һәм кадрлар һәм дәүләт хезмәте бүлеге печате сугылган күчермәсен имза куйдырып тапшыра. Гаризаның министр имзасы куелган төп нөсхәсе граждан хезмәткәренең шәхси делосына теркәлә.

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләренең коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт
алу тәртибенә 1 нче кушымта

Татарстан Республикасы
юстиция министрына

___________________________________

____________________________________
(Ф.И.Ә.и., вазыйфасы һәм структур

____________________________________
бүлекчә, яшәү урыны адресы

____________________________________
телефон номеры)

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләренең коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт
алулары турында гариза

Миңа түләүсез нигездә
______________________________________________________________________
(оештыру-хокукый формасы, исеме, ИНН, адрес)

белән идарә итүдә
______________________________________________________________________
(бердәнбер башкарма органның яки идарә итүнең коллегиаль органының исеме)

сыйфатында катнашуга рөхсәт бирүегезне сорыйм.

_______________ _________________ ______________________________
(дата) (имза) (фамилия, инициаллар)

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында
Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләренең коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт
алу тәртибенә 2 нче кушымта

Татарстан Республикасы
Юстиция министрлыгында Татарстан Республикасы дәүләт граждан
хезмәткәрләренең коммерцияле
булмаган оешмалар белән идарә итүдә
түләүсез нигездә катнашуга рөхсәт
алулары турында гаризаларны теркәү

ЖУРНАЛЫ

| № п/п | Теркәү датасы | Гариза бирүченең Ф.И.Ә.и. | Гариза бирүченең имзасы | Җаваплы затның Ф.И.Ә.и. | Җаваплы затның имзасы |
|---|---|---|---|---|---|
| | | | | | |
| | | | | | |